| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 Казан ш. № 679-31/э-2021

2022 елга Татарстан Республикасы халкы һәм аңа тиңләштерелгән кулланучы категорияләре өчен электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) киметү коэффициентларын куллану турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 гыйнварыннан башлап 2022 елның 30 июненә кадәр шәһәр торак пунктларында стационар электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыта торган җайланмалар белән тәэмин ителгән йортларда яшәүче халык өчен электр энергиясенә булган бәяләргә (тарифларга) 0,7183 киметү коэффициенты кулланыла дип билгеләргә.

2. 2022 елның 1 июленнән башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр шәһәр торак пунктларында стационар электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыта торган җайланмалар белән тәэмин ителгән йортларда яшәүче халык өчен электр энергиясенә булган бәяләргә (тарифларга) 0,7442 киметү коэффициенты кулланыла дип билгеләргә.

3. 2022 елның 1 гыйнварыннан башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр авыл торак пунктларында яшәүчеләр өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата 0,7 киметү коэффициенты кулланыла дип билгеләргә.

4. 2022 елның 1 гыйнварыннан башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасында кулланучыларның халыкка тиңләштерелгән категорияләре өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметү

коэффициентлары әлеге карар кушымтасына туры китереп кулланыла, дип билгеләргә.

5. 2022 елның 1 гыйнварыннан башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр, шушы карарның 4 пунктында күрсәтелгән кулланучылардан тыш, Татарстан Республикасында халыкка тиңләштерелгән кулланучылар өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) карата киметү коэффициенты кулланылмый, дип билгеләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В. Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2021 № 679-31/э-2021 карарына кушымта

2022 елга Татарстан Республикасы буенча халыкка тиңләштерелгән кулланучы категорияләре өчен электр энергиясе өчен бәяләргә (тарифларга) киметү коэффициентлары

| т/с | Халыкка тиңләштерелгән кулланучы категорияләре | Киметә торган коэффициентлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | I яртыеллык | | II яртыеллык | |
| | | стационар электр плитәләре һәм (яки) электр энергиясе белән җылыта торган җайланмалар урнаштырылган урыннарда шәһәр торак пунктларында булган | авыл торак пунктларында булган | стационар электр плитәләре һәм (яки) электр энергиясе белән җылыта торган җайланмалар урнаштырылган урыннарда шәһәр торак пунктларында булган | авыл торак пунктларында булган |
| 1 | Коммерциясез бакчачылык ширкәтләре һәм коммерциясез яшелчәчелек ширкәтләре | 0,7183 | 0,7 | 0,7442 | 0,7 |
| 2 | Килүчеләр хисабына тотыла торган дини оешмалар. | - | 0,7 | - | 0,7 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге